СОВЕТ
МАЛОЦИЛЬНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЕЧЕ
ЧЫНЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Тел.: (84375) 39-3-35; 39-4-72, факс: (84375) 39-3-35, e-mail: MceI.Drz@tatar.ru,

РЕШЕНИЕ *с.Малая Цильна* КАРАР

2022 нче елнын 15 нче ноябре № 23/4

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советы Уставы нигезендә, Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы карар итте:

1. «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 нче ноябрендәге 50/4 номерлы (2020 елның 19 нчы маендагы №55/3 редакциясендә) карарының **4 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәп,** үзгәреш кертергә:

«4) Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге территориясендә яшәүче Россия Федерациясе гражданнары.

2. Әлеге карарны Кече Чынлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Кече Чынлы авыл җирлегенең сайтында урнаштырырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Кече Чынлы авыл җирлеге Советының 2019 елның 15 ноябрендәге 50/4 номерлы (әлеге карар редакциясендә) карарының 4 пунктындагы 4 пунктчасы нигезләмәләренең гамәлдә булуы 2021 елның салым чорында җир салымын исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Кече Чынлы авыл җирлеге башлыгы: Г.Ш.Халитов